**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

«14» июнь 2019 с. Тюлячи № 182

Теләче муниципаль районында 2019 елда өлкән яшьтәге кешеләрне компьютер белеменә өйрәтүне оештыру турында

Татарстан Республикасында 2017-2020 елларга Россия Федерациясендә 2025 елга кадәр өлкән буын гражданнар мәнфәгатьләрендәге гамәлләр стратегиясенең беренче этабын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 30 декабрендәге 3172 номерлы күрсәтмәсе белән расланган чаралар планы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, өлкән яшьтәге кешеләрне актив яшәү рәвешенә җәлеп итү максатларында,

1. Теләче муниципаль районы муниципаль учреждениеләре базасында пенсия алды яшенә һәм пенсия яшенә җиткән эшләмәүче затларны «Өченче буын университеты» программасы буенча заманча белем нигезләренә өйрәтүне оештырырга.

2. «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына (Карпова Н.В.) ведомство карамагындагы учреждениеләр базасында әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән затларны укытуны оештыруда ярдәм күрсәтергә, шулай ук укытучылар төркемен формалаштырырга, уку төркемнәрен оештырырга, уку планын, укыту программасын эшләргә һәм дәресләрне вакытында үткәрүне тәэмин итәргә.

3. Теләче районы ветераннар Советы (пенсионерлар) иҗтимагый оешмасына, Пенсия фондының Теләче районы бүлегенә, «Теләче районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә белем бирүне оештыру, компьютер белеменә өйрәнергә теләгән эшләмәүче пенсионерлардан гаризалар кабул итү турында халыкка җиткерүне, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша да, тәкъдим итә.

4. Пенсия фондының Теләче районы бүлеге клиент хезмәте җитәкчесе (Сабирҗанова Р.Р.) әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән «Өченче буын университеты» программасы кысаларында заманча белем нигезләренә өйрәнергә теләүче затлардан гаризалар кабул итүне оештыруны тәкъдим итәргә.

5. Әлеге күрсәтмәне Теләче муниципаль районының Интернет мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ә. Нурмөхәмәтовка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хамидуллин